ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“05” октябрь 2020 ел** **№20**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясенең җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылмаларны сүтү, күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (сүтү) тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту эшләрен оештыру максатыннан, Россия Федерациясе Җир кодексының 60, 62, 76 статьяларына, Россия Федерациясе Граждан кодексының 222 статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясенең җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылмаларны сүтү, күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (сүтү) тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Арча муниципаль районы
Иске Кырлай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
05.10.2020 ел, № 20
карарына 1нче кушымта

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясенең җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылмаларны сүтү, күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (сүтү) тәртибе турында**
**Нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем ала алырлык булуы, шулай ук үзбелдекле төзелгән корылмаларны сүтү, күчемле милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (сүтү) турындагы карарларның законлылыгы принципларына таяна һәм, оештыру-хокукый формасына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, барлык граждannар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш.

1.3. Әлеге Нигезләмә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә яисә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә, муниципаль милектәге башка күчемсез милектә үзбелдекле төзелгән корылмаларны җимерү һәм күчерү (сүтү) тәртибен регламентлый.

1.4. Законсыз урнаштырылган күчемле милек - законнарда, норматив хокукый актларда каралган хокукый нигезләрсез һәм/яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып, шул исәптән күчемсез милек булып тормаган вакытлыча объектны (-лар) урнаштыру тиешле шартнамәдә каралмаган булса, шулай ук аны урнаштыру хокукы туктатылган очракта, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә (күчемсез милектә) урнаштырылган күчемле объект (шул исәптән вакытлыча төзелгән).

1.5. Күчемле милек булып түбәндәге төрдәге күчемле милек санала: стационар булмаган сәүдә объектлары (вакытлы корылмалар, вакытлы конструкцияләр һәм күчмә корылмалар), контейнерлар, күчмә корылмалар һәм корылмалар, конструкцияләр, механизмнар, төзелеш материаллары, киртәләр, ачык типтагы автостоянкалар һәм башка күчемле милек:

1) павильон-капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товар запасын саклау өчен бүлмәсе булган, бер яки берничә эш урынына исәпләнгән аерым торучы стационар булмаган объект (шул исәптән кафе, шиномонтаж остаханәләре, машина югычлар, тукталыш комплекслары, стационар бәдрәфләр);

2) киоск- капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товарларны саклау өчен бүлмәсе булмаган, бер эш урынына исәпләнгән аерым торучы стационар булмаган объект;

3) телекоммуникация контейнеры - технологик җиһазлар: автоном телефон станцияләре, телефон концентраторлары, телематик төеннәр, мәгълүмат тапшыру

төеннәре, мәгълүмат пакетларын маршрутлаштыру төеннәре, мәгълүмат тапшыру челтәрләре буенча сөйләм мәгълүматын тапшыру төеннәрен урнаштыру өчен билгеләнгән металл конструкцияләрдән торган контейнер тибындагы вакытлыча корылма;

4) металл гараж - капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм автотранспорт чарасын ябу өчен билгеләнгән күчемсез милек объекты булмаган стационар булмаган объект;

5) контейнер - капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, товарлар салу өчен урыны булган тулысынча яки өлешчә ябык савыттан гыйбарәт транспорт җиһазы (читлек, төшерү цистернасы яки шундый җайланмалар);

6) койма- капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, киртәләү сыйфатында кулланыла торган металл, агач яки башка материалдан ясалган конструкция;

7) теплица - капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, яктылык үтә торган материалдан ясалган өслекле, теплица культураларын һәм үсентеләрен үстерү өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

8) саклагыч бүлмә (кладовая) - капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, азык-төлек продуктлары, утын, эш кораллары саклау өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

9) сарай-капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, хуҗалык милеген саклау, йорт хайванын тоту өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

10) будка - капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, эшчеләр һәм каравылчылар тору өчен урын буларак файдаланыла торган стационар булмаган объект.

1.6. Законсыз урнаштырылган күчемсез милек - Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә (күчемсез милектә), законнарда, норматив хокукый актларда билгеләнгән хокукый нигезләрсез һәм/яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып, законсыз рәвештә урнаштырылган күчемсез милек.

Үзбелдекле төзелгән корылма дип билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән җир кишәрлегендә төзелгән яисә әлеге обектны төзү бу җир кишәрлегендә рөхсәт ителмәгән яки төзелеш башланган көнгә һәм үзбелдекле корылма төзелү ачыклану көненә гамәлдә булган законлы килешүләр, рөхсәтләр алынмыйча төзелгән яисә шәһәр төзелеше һәм төзелешләр нормалары һәм тәртипләре сакланмыйча төзелгән бина, корылма яки башка төзелмә санала.

1.7. Законсыз урнаштырылган үзбелдекле төзелмәләрне җимерү, күчемсез милекне, стационар булмаган объектны сүтү (күчерү) мәсьәләләрен Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карый.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылмаларны, стационар булмаган объектларны ачыклау буенча эшне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты каршында төзелгән законсыз рәвештә урнаштырылган корылмаларны ачыклау һәм сүтү буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) алып бара.

Комиссия эшчәнлеге әлеге Нигезләмә һәм Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган корылмаларны, стационар булмаган объектларны ачыклау һәм сүтү комиссиясе турындагы Нигезләмә белән регламентлана.

1.8. Һәр очракта үзбелдекле төзелгән һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемсез мөлкәтне, стационар булмаган объектны ачыклау акт белән рәсмиләштерелә, анда актны төзү датасы, вакыты; объектны ачыклаган затның (затларның) исеме, фамилиясе, атасының исеме һәм вазыйфасы; ачыкланган объектның урнашу урыны; ачыкланган хокук бозулар, затлар турында белешмәләр (әгәр андый очраклар ачыкланса), таләпләре бозылган норматив хокукый актның статьялары һәм пунктлары; үзбелдекле төзелгән объектны ачыклаганда катнашкан затларның акт белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында белешмәләр, аларның имзалары яки имза салудан баш тарту турында һәм башка белешмәләр (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә үзбелдекле төзелгән корылма, законсыз урнаштырылган күчемле милек, стационар булмаган объектларны ачыклау турында акт төзегәндә, Комиссия ачыкланган стационар булмаган объектны урнаштырган затны (граждан яки юридик зат) ачыклау өчен чаралар күрә һәм әлеге затны Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган корылма ачыклану турындагы акт белән таныштыра. Үзбелдекле төзелгән бинаны законсыз урнаштырган зат акт белән танышудан баш тарткан очракта, актта тиешле язма ясала.

Әлеге Нигезләмә кысаларында, ачыкланган үзбелдекле корылманы урнаштыручы зат булып үзбелдекле корылманы төзүче һәм (яки) үзбелдекле төзелгән корылмадан файдаланучы граждан яки юридик зат санала.

Үзбелдекле төзелгән корылманы, стационар булмаган объектны урнаштырган зат ачыкланмаган очракта, шулай ук ачыклау мөмкин булмаган очракта, аны сүтү, ташу һәм саклау әлеге Нигезләмәнең 1.15 пунктында каралган тәртиптә башкарыла һәм бу хакта актта күрсәтелә.

1.9. Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз үзбелдекле төзелгән корылма ачыклану турында акт төзелгәннән соң, Комиссия үзбелдекле төзелеш алып барган затка әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча корылманы сүтү турында таләп җибәрә.

Законсыз рәвештә урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү турында таләп корылманы урнаштырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) шәхси имза куйдырып тапшырыла яисә Комиссия тарафыннан ачыкланган адреска тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы хат итеп почта аша җибәрелә.

Законсыз рәвештә үзбелдекле төзелгән корылманы урнаштырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) аны сүтү турында таләпне тапшыру белән берүк вакытта, таләп, әйләнә-тирә мохит йогынтысына тотрыклы махсус чаралар белән ясалган язу юлы белән, законсыз рәвештә төзелгән корылмага языла.

Законсыз рәвештә үзбелдекле корылма төзегән зат (граждан яки юридик затның вәкаләтле вәкиле), аны сүтү турында таләп алынганнан соң ике атна эчендә, үз көче белән һәм үз хисабына законсыз рәвештә төзелгән корылманы сүтәргә тиеш.

1.10. Граждан яисә юридик зат тарафыннан законсыз рәвештә төзелгән корылманы сүтү турында таләп үтәлмәгән очракта, Комиссия үзбелдекле төзелгән корылманы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты көче белән сүтү турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә милекне эвакуацияләү һәм саклау буенча хезмәтләр күрсәтү өчен оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

1.11. Законсыз рәвештә үзбелдекле корылма төзегән затка Комисия тарафыннан сүтү датасы турында әлеге Нигезләмәнең 1.9 пунктында билгеләнгән тәртиптә әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасындагы форма буенча хәбәрнамә тапшырыла (җибәрелә).

1.12. Законсыз урнаштырылган объектны сүтү, ташу һәм саклау Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты белән муниципаль контракт төзегән зат тарафыннан (алга таба - Оешма) комиссия әгъзалары катнашында башкарыла.

Сүтү һәм транспорт белән ташу ысулын сайлау өчен җаваплылык Оешмага йөкләнә. Оешма вәкиле һәм (яки) комиссия фикеренчә, законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү аны җимермичә мөмкин булмаса, бу хакта Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү актында билге ясала.

Законсыз урнаштырылган корылманы сүтү процедурасын теркәү өчен фото-яки видеога төшерүнең техник чаралары кулланыла.

Законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтәр алдыннан Комиссия анда булган мөлкәтне тасвирларга тиеш. Милек исемлеге төзелә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Ул Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылманы сүтү турындагы актка кушымта булып теркәлә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылманы сүтү турындагы акт әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасындагы форма буенча законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү тәмамланганнан соң төзелә.

Актка рөхсәтсез үзбелдекле төзелгән корылма урнаштырган зат (граждан яки юридик затның вәкаләтле вәкиле) кул куя. Үзбелдекле урнаштырылган корылманы сүткән вакытта аның булмавы яки ул актка имза куюдан баш тарткан очракта, актта тиешле язма ясала.

1.13. Законсыз урнаштырылган сүтелгән төзелмә һәм мөлкәт тасвирламасы нигезендә сүтелгән вакытта анда булган мөлкәт, сүтелгән стационар булмаган объектларны урнаштыру урынына чыгарылырга тиеш, анда муниципаль контракт буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль контракт буенча әлеге мөлкәтне саклау тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Оешма, ташу һәм саклау вакыты дәвамында сату срогы чыккан яки саклау шартларын бозу аркасында яраксызга чыккан яисә сүтүгә кадәр яраксызга әйләнгән товарлар өчен җавап тотмыйлар.

1.14. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны сүтү чаралары белән бәйле чыгымнарын каплаганнан соң, законсыз урнаштырылган сүтелгән төзелмә һәм сүтелгән вакытта анда булган мөлкәт тасвирламасы буенча мөлкәт законсыз рәвештә үзбелдекле корылма төзегән затка кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының әлеге пунктта күрсәтелгән чыгымнары законсыз рәвештә үзбелдекле корылма төзегән зат тарафыннан тулы күләмдә яисә суд тәртибендә кире кайтарылырга тиеш.

1.15. Үзбелдекле төзелгән корылманы рөхсәтсез урнаштырган затны ачыклау мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты Арча муниципаль районының рәсми сайтында, «Арча хәбәрләре» (“Арский вестник”) район газетасында законсыз

урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылманы хәбәр ителгәннән соң ике атна эчендә ирекле сүтү һәм җир кишәрлеген азат итү турындагы тәкъдим белән мәгълүмат урнаштыра.

Мәгълүмати хәбәр урнаштыру белән берүк вакытта Комиссия законсыз урнаштырылган корылмага хәбәр ителгәннән соң ике атна эчендә ирекле сүтү һәм җир кишәрлеген азат итү турында әйләнә-тирә мохит йогынтысына тотрыклы махсус чаралар белән таләп яза, шулай ук законсыз рәвештә үзбелдекле корылма төзегән затны ачыклау максатыннан хокук саклау органнарына запрос җибәрә.

Әгәр Комиссия тарафыннан территориядә законсыз төзелгән корылма ачыклану турында акт төзелгәннән соң 14 көн эчендә законсыз корылма урнаштырган зат ачыкланмаса, Комиссия законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү турында карар кабул итә.

Законсыз урнаштырылган корылманы сүтү әлеге Тәртипнең 1.12. пунктында каралган тәртиптә башкарыла.

Законсыз урнаштырылган корылманы сүтү, аны саклау урыны һәм вакыты турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан «Арча хәбәрләре» ("Арский вестник") район газетасында басылып чыга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Законсыз урнаштырылган сүтелгән корылма һәм мөлкәт исемлеге буенча сүтелгән вакытта анда булган мөлкәт, стационар булмаган объектны урнаштырган зат гаризасы буенча, әлеге Нигезләмәнең 1.14 пунктында каралган тәртиптә Башкарма комитетның «Арча хәбәрләре» ("Арский вестник") район газетасына чыгымнарын каплаганнан соң кире кайтарылырга тиеш.

1.16. Кирәксез законсыз урнаштырылган сүтелгән корылма һәм сүтелгән вакытта анда булган мөлкәт Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты белән килешү нигезендә өч ай сакланырга тиеш.

Өч ай үткәннән соң законсыз урнаштырылган сүтелгән стационар булмаган объект хуҗасы ачыкланмаса, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты стационар булмаган объектка ия була һәм стационар булмаган объектны хуҗасыз дип тану һәм аны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә юк итү өчен муниципаль милеккә тапшыру турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

Суд карары стационар булмаган объектның бәясе биш тапкыр минималь хезмәт хакы күләменә туры килә торган суммадан түбәнрәк булган очракта таләп ителми.

## 2. ЗАКОНСЫЗ УРНАШТЫРЫЛГАН КҮЧМӘ ОБЪЕКТЛАРНЫ ҺӘМ МАТДИ КЫЙММӘТЛӘРНЕ САКЛАУ, ТРАНСПОРТ БЕЛӘН ТАШУ ҺӘМ ЮК ИТҮ

2.1. Вакытлыча саклау урыннарына тапшырылган үзбелдекле төзелгән (законсыз) объектлар һәм башка мөлкәт, объектларга хокукны раслаучы документлар, шулай ук әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән үзбелдекле төзелмәләрне сүтү, җимерү һәм законсыз урнаштырылган объект һәм мөлкәтне саклау, шулай ук күрсәтелгән мөлкәтне калдыклар сыйфатында транспорт белән ташу һәм юк итү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны кайтаруны раслаучы документлар тапшырылганнан соң, хуҗасына кайтарыла.

Мөрәҗәгать иткән көнне, әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тикшергәннән соң, саклау өчен җаваплы зат рөхсәтсез (законсыз) объектлар һәм башка мөлкәтне вакытлыча саклау урыныннан бирү мөмкинлеген килештерү турында тамга белән, хуҗага тапшыру-кабул итү акты бирә.

Үзбелдекле (законсыз) объектны һәм башка милекне тапшырганда тапшыру-кабул итү актына Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге

Башкарма комитетының вазыйфаи заты, саклау өчен җаваплы зат, үз белдекле (законсыз) объект хуҗасы тарафыннан кул куела. Актның бер нөсхәсе үзбелдекле (законсыз) объект хуҗасында, икенчесе - саклау өчен җаваплы затта, өченчесе – Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.

2.2. Сүткәннән соң сакланган объектны һәм башка мөлкәтне алу өчен объект хуҗасы саклауны башкаручы затка язма гариза белән мөрәҗәгать итә, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

2.2.1. Законсыз урнаштырылган объектны һәм объектта булган мөлкәтне сүтү, җимерү, күчерү һәм саклау, шулай ук әлеге мөлкәтне калдыклар сыйфатында транспорт белән ташу һәм юкка чыгару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны раслаучы түләү документы күчермәсе.

2.2.2. Объектларга һәм милеккә хокукны раслаучы документлар (сату-алу, бүләк итү, аренда һәм башка документлар) һәм объектка милек хокукын раслаучы һәм анда булган мөлкәткә хокукны раслаучы башка документлар күчермәләре.

2.3. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар суммасы үзбелдекле (законсыз) объект хуҗасы тарафыннан объект урнашкан җирлек бюджетына күчерелә.

Законсыз урнаштырылган объектларны сүтү, җимерү, күчерү, саклау, транспорт белән ташу һәм юкка чыгару, шулай ук үзбелдекле төзелгән һәм законсыз урнаштырылган күчемсез объектларда урнашкан мөлкәтне саклау, транспорт белән ташу һәм юк итү юридик яки физик зат тарафыннан хезмәт күрсәтү турындагы килешү нигезендә түләүсез гамәлгә ашырылган очракта, үзбелдекле (законсыз) объектның законлы хуҗасы тарафыннан чыгымнарны каплау әлеге чараларны гамәлгә ашыручы зат белән башкарыла.

Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау күләме, факттагы саклау вакытына карап, чыгымнарның факттагы суммасыннан чыгып исәпләнә.

2.4. Әгәр хуҗасы вакытлыча саклау урынында саклануччы мөлкәт буенча бер ел дәвамында мөрәҗәгать итмәсә, мөлкәт Россия Федерациясе Граждан кодексында каралган тәртиптә муниципаль милеккә күчерелергә мөмкин һәм аннан соң үзбелдекле объектларны сүтүгә, мөлкәтне күчерүгә һәм аны саклауга бәйле чыгымнарны кайтару максатыннан, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә сатылырга мөмкин.

## 3. ҮЗБЕЛДЕКЛЕ ТӨЗЕЛГӘН КОРЫЛМАЛАРНЫ СҮТҮ, ЗАКОНСЫЗ УРНАШТЫРЫЛГАН КҮЧМӘ ОБЪЕКТЛАРНЫ КҮЧЕРҮ (ҖИМЕРҮ), САКЛАУ, ТРАНСПОРТ БЕЛӘН ТАШУ ЯКИ ЮК ИТҮ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЧЫГЫМНАР

3.1. Рөхсәтсез (законсыз) объектларны һәм сүтелгән объектларда булган мөлкәтне сүтү, күчерү, саклау, аларны калдыклар сыйфатында транспорт белән ташу һәм юк итү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү әлеге чараларны гамәлгә ашыручы затлар исәбеннән гамәлгә ашырыла, алга таба чыгымнарны үзбелдекле (законсыз) объект хуҗасы каплый.

3.2. Үзбелдекле төзелгән объектларны сүтү, күчерү, саклау, аларны транспорт белән ташу һәм юк итү "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль контракт төзелгән юридик яки физик зат тарафыннан түләүле нигездә башкарылган булса, чыгымнар күләмен исәпләү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге
территориясендә үзбелдекле төзелгән
корылманы ачыклау һәм сүтү турындагы
Тәртипкә 1 нче кушымта

**АКТ № _______**

"__" ________ 20___ ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге
территориясендә үзбелдекле төзелгән
корылманы ачыклау турында

Комиссия составы

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________
(әлеге актны төзегән комиссия әгъзаларының ф. и. а.и.,вазыйфасы)

_______________________________________________
(стационар булмаган объектның адресы һәм урыны)

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз рәвештә урнаштырган затның ф.и. а.и. һәм адресы вәкаләтле затның исеме, адресы, ф. и. а.и. һәм вазыйфасы - юридик зат өчен)

_______________________________________________,
(үзбелдеге төзелмәнең исеме)

_______________________________________________

Әлеге җир кишәрлеге гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә стационар булмаган объектны урнаштыру өчен Россия Федерациясенә бирелмәде.

Акт белән таныштым_______________________________________
(үзбелдекле корылмалар төзегән затның ф. и. а.и., граждан яисә юридик вәкаләтле вәкил вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе_______________________________________

Комиссия әгъзалары _______________________________________

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге
территориясендә үзбелдекле төзелгән
корылманы ачыклау һәм сүтү турындагы
Тәртипкә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү турында**
**Таләп**

"__" ________ 20___ ел

Бирелде________________________________________________

________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затлар: Ф. и. а.и.-граждан өчен;
үзбелдекле төзелгән корылма стационар булмаган объект исеме, адресы (юридик зат өчен)

________________________________________________

________________________________________________
(законсыз урнаштырылган объектның исеме)

адрес буенча урнашкан:_________________________________

Комиссия составы:

________________________________________________

________________________________________________

________________________________________________
(Ф. и. а.и., комиссия әгъзалары вазыйфасы)

Арча муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган объектны законсыз урнаштыру ачыклану турында акт төзелде

________________________________________________

________________________________________________
(актның датасы һәм номеры)

"___" __________ 20__елга кадәр Сезнең көч һәм акчаларыгыз хисабына законсыз урнаштырылган корылманы (төзелешнең исеме) сүтүне таләп итәбез.

Комиссия карары буенча объект 10 календарь көн дәвамында мәҗбүри тәртиптә сүтеләчәк һәм чыгарылачак. Законсыз урнаштырылган объектны сүтү, ташу һәм саклау буенча барлык чыгымнар Сездән РФ законнарында каралган

тәртиптә түләттереләчәк.

Әлеге таләпнең үтәлеше турында Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетына "__" ________ 20__ елга кадәр хәбәр итүегезне сорыйбыз.

Таләп алынды_______________________________________________

(стационар булмаган объектны үзбелдекле урнаштырган затның ф.и.а.и., граждан яисә юридик вәкаләтле вәкил вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе: ____________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары: ____________________________________

(имза

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге
территориясендә үзбелдекле төзелгән
корылманы ачыклау һәм сүтү турындагы
Тәртипкә 3 нче кушымта

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы сүтү датасы турында Хәбәрнамә №**

Комиссия составы

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________
(Ф. и. а.и., комиссия әгъзалары вазыйфасы)

хәбәр итә ______________________________________________

______________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз рәвештә урнаштырган затның ф.и. а.и. һәм адрес-<url>
вәкаләтле затның исеме, адресы, Ф. и. а.и. һәм вазыйфасы - юридик зат өчен)

законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны сүтү

______________________________________________________
(объектның адресы һәм атамасы)

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты көче белән

______________________________________________________ булачак
(дата һәм Мәскәү вакыты)

Хәбәр алынды ______________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затның ф.и.а.и., граждан яисә юридик вәкаләтле вәкил вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе: ________________________________________
(имза)

Комиссия әгъзалары:

______________________________________________________
(имза)

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге
территориясендә үзбелдекле төзелгән
корылманы ачыклау һәм сүтү турындагы
Тәртипкә 4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылманы сүтү**
**Акты №**

"__" ________ 20___ ел

Комиссия составы

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________
(Ф. и. а.и., комиссия әгъзалары вазыйфасы)

һәм ______________________________________________

______________________________________________
(Ф. и. а.и., граждан яисә юридик вәкаләтле вәкил вазыйфасы, имзасы)
законсыз урнаштырылган үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү башкарылды

______________________________________________

______________________________________________
(төзелмә атамасы)

______________________________________________

______________________________________________

адрес буенча урнашкан:

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(Ф. и. а.и. яки объектны сүткән юридик затның исеме)
Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә законсыз урнаштырылган корылманы ачыклау турындагы ____________ ел №__ акт, җир кишәрлеген азат итү турында __________ ел, №__ таләп, законсыз урнаштырылган корылманы сүтү буенча Комиссиянең ______________ел, №___ карарын үтәү нигезендә законсыз урнаштырылган корылма сүтеп алынды.

Объектның тышкы хәле:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Объектны ачу эшләре башкарылмады (башкарылды).

Объектны сүтү эшләре башкарылмады (эшләнде).

Мәҗбүри сүтелгән стационар булмаган объект

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(адресы)

Урнаштырылды һәм җаваплы саклауга тапшырылды.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(исеме, Ф. и. а.и., вазыйфасы)

Әлеге акт 3 нөсхәдә төзелде һәм тапшырылды (җибәрелде):
Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетына;
- үзбелдекле корылма төзегән затка (гражданинга яисә юридик затка)

______________________________________________________________________
(объектны саклауга кабул иткән затның исеме)

Акт белән таныштым

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затның ф. и. а.и., граждан яисә юридик вәкаләтле вәкил вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе________________________________________
(имза)
Комиссия әгъзалары: _____________________________________
(имза)
Объектны саклауга кабул иткән зат:___________________________________
(имза)